| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 12 декабрь г.Казань № 1137

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының тәңгәллеген билгеләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» 2003 ел, 29 май, 295 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының тәңгәллеген билгеләү комиссиясе составына үзгәреш кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының тәңгәллеген билгеләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» 2003 ел, 29 май, 295 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2003 ел, 21 июль, 381 нче; 2009 ел, 23 ноябрь, 795 нче; 2011 ел, 21 гыйнвар, 36 нчы; 2012 ел, 10 май, 364 нче; 2019 ел, 16 июль, 584 нче; 2020 ел, 4 ноябрь, 992 нче; 2023 ел, 21 март, 301 нче; 2023 ел, 18 июль, 858 нче; 2024 ел, 12 октябрь, 879 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының тәңгәллеген билгеләү комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

Комиссия составына Татарстан Республикасы юстиция министры урынбасары Марат Фәрид улы Низамиевны кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы халкын адреслы социаль яклау программасында каралган балалы гаиләләргә һәм халыкның аз тәэмин ителгән башка категорияләренә социаль ярдәм буенча чараларны көчәйтү турында» 1994 ел, 21 февраль, 69 нчы;

«Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлегенә дәүләт пенсияләрен билгеләү һәм түләү вәкаләтләрен тапшыруны оештыру турында» 2000 ел, 15 декабрь, 855 нче;

«Дәүләт пенсияләрен, пенсияләргә өстәмә түләүләр билгеләү һәм түләү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өлешендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2003 ел, 5 июнь, 304 нче;

«Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлегенә дәүләт пенсияләре билгеләү һәм түләү вәкаләтләрен тапшыруны оештыру турында» 2000 ел, 15 декабрь, 855 нче карары белән расланган Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлегенә тапшырыла һәм Татарстан Респуб-ликасының Социаль тәэминат министрлыгы һәм республика шәһәрләре, районнары администра-цияләренең халыкны социаль яклау органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт пенсияләре һәм пособиеләр билгеләү, аларны яңадан исәпләп чыгару һәм түләү вәкаләтләре исемлегенә үзгәреш кертү хакында» 2014 ел, 14 октябрь, 755 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин